КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 апрель г.Казань № 267

«Ак Чишмә» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 423308, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Осиновый Гай авылы, Родниковая урамы, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан «Ак Чишмә» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Ак Чишмә» үзәге) 2019 елның 1 июленнән бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

бу карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә:

«Ак Чишмә» үзәген бетерү комиссиясе составын расларга;

«Ак Чишмә» үзәген бетерү тәртибен һәм вакытларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

«Ак Чишмә» үзәген бетерү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен «Ак Чишмә» үзәгенең бетерелү процессында булуы турындагы мәгълүматларны теркәүче органга кертергә;

бу карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә бетерелә торган учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез мөлкәтне алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне, шулай ук күчемсез мөлкәт объектларының

техник документларын Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

«Ак Чишмә» үзәге бетерелү аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә, шулай ук аны бетерү буенча законнар белән күздә тотылган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. «Ак Чишмә» үзәге йөкләмәләре, шул исәптән суд карарларын үтәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы булып «Ак Чишмә» үзәген гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына ике ай эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кертелгән исемлек нигезендә «Ак Чишмә» үзәгенә элегрәк беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен законнар белән билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.

5. «Ак Чишмә» үзәген бетерү чаралары үткәрелгәннән соң калган акча Татарстан Республикасындагы социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр исемлегенә кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә субсидияләр рәвешендә грантлар бирүгә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны компенсацияләүгә (каплауга) җибәрелә дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр кертергә.

7. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә бу карарның 2 нче һәм 4 нче пунктларында күрсәтелгән барлык чараларны төгәлләгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында Татарстан Республикасының тиешле норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 819 нчы карарына тиешле үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин